ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2021 елның 15 апреле** **Чистай шәһәре** **№ 217**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 25 октябрендәге 572 номерлы карары белән расланган Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектын сүтүне төгәлләү һәм бу хакта региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеге органына хәбәр итү турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында.

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 25 октябрендәге 572 номерлы карары белән расланган Шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектын сүтүне төгәлләү һәм бу хакта региональ дәүләт төзелеш күзәтчелеге органына хәбәр итү турында муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» бүлегенең 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган бүлмәләргә, гариза бирүчеләрнең көтү һәм кабул итү урынына, шул исәптән Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законы нигезендә әлеге объектларга инвалидлар өчен керү мөмкинлеген тәэмин итүгә, әлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм кирәкле янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә мәгълүмат стендлары белән документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителә. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматын урнаштыруга һәм бизәүгә карата таләпләр | мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br>Инвалидларга, шул исәптән кресло-колярскалардан һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидларга бина, бүлмәләр һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану шартлары тәэмин итү чаралары гамәлгә ашырыла, шул исәптән:<br>- биналарга һәм бүлмәләргә, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләргә тоткарлыксыз керү өчен шартлар;<br>- элемтә һәм мәгълүмат чараларыннан тоткарлыксыз файдалану өчен шартлар;<br>- объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү, шул исәптән кресло-коляска кулланып, мөмкинлеге;<br>- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләренә ия булган инвалидларны озатып бару һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;<br>- инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, бинага, бүлмәләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне тиешенчә урнаштыру;<br>-инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлы-ноктал шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәчегә рөхсәт;<br>- бинага һәм бүлмәгә үткәрүче этне кертү, аны махсус укытуны раслый торган һәм формасы буенча бирелә торган һәм дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру, халыкны социаль яклау өлкәсендә норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә бирелүче документ булганда;<br>- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга хезмәт | |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтү, киртәләрне җиңеп чыгу, аларга хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы башка затлар белән беррәттән ярдәм күрсәтү.» | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазифаларын башкаручы П.Б. Емельянов